КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 октябрь г.Казань № 841

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә мәгълүмат урнаштыру тәртибен раслау турында» 2025 ел, 21 июль, 535 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә мәгълүмат урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә мәгълүмат урнаштыру тәртибен раслау турында» 2025 ел, 21 июль, 535 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә мәгълүмат урнаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка «кергән көненнән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Рәсми сайтта белешмә урнаштыру өчен мәгълүмат материаллары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан әзерләнә һәм квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, рәсми сайтта урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин